**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 2** **10.12.2019**

Татарстан Республикасы Азнакай
муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге
составына керүче Тымытык авылында
2020 елда гражданнарның үзара салымын
кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Тымытык авыл җирлеге Тымытык авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Тымытык авыл җирлеге Тымытык торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 200 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлдерергә:

- Тымытык авылы М. Җәлил урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Тымытык авылында Чапаев ур., Свердлов ур., Яшьләр ур., Кече Бакча ур., Яңалиф ур. буенча вак таш белән юлларның чокырларын ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Тымытык авылында юл билгеләре сатып алу;
- Тымытык авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;
- Тымытык авылы территориясендә җыештыру, көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарларны вакытлыча җыю, чистарту;
- Тымытык авылында «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авыл мәдәният йортында өлешчә косметик ремонт;
- Тымытык авылында спорт чараларын үткәрү өчен бүләк, сувенир продукциясе сатып алу;
- Тымытык авылындагы юлларны кардан чистарту;
- Тымытык авылында җәйге чорда территорияләрне чабу;

- Тымытык авылында коры агачлар, куаклар  киселү;
- Тымытык авылында урам исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу (әзерләү) һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Тымытык авылы, Тельман урамы, 62Б нчы йорт, 75 нче йорт.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Тымытык авыл җирлеге Башлыгы Э.Х. Гыйләҗева